**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«_27__» ___10___ 2023 ел.** **№ __276__**

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 29 декабрендәге 381 номерлы «Опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында (16.10.2019 №300, 09.12.2019 №352, 01.10.2020 №257, 02.04.2021 №74, 06.07.2021 №148 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 24 июлендәге 386-ФЗ номерлы федераль законны үтәү йөзеннән карар бирә:

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының «Опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламенты турында» 2018 елның 29 декабрендәге 381 номерлы (16.10.2019 №300, 09.12.2019 №352, 01.10.2020 №257, 02.04.2021 №74, 06.07.2021 №148 карарлар редакциясендә) карары белән расланган “Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка (кызлыкка) алучыга кандидат буларак исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты»ның 12 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.9 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Әгәр мөрәҗәгать итүче (ләр) түбәндәге категорияләргә караса:<br>1) суд тарафыннан эшкә сәләтсез яки чикләнгән рәвештә эшкә сәләтсез дип танылган затлар;<br>2) берсе суд тарафыннан эшкә сәләтсез яки чикләнгән рәвештә | Россия Федерациясе Гаилә кодексының 127 статьясы<br><br>РФ Хөкүмәтенең 275 номерлы карары |

| | | |
|---|---|---|
| | эшкә сәләтсез дип танылган ир белән хатын;<br>3) суд нигезендә ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән яки ата-ана хокукларында чикләнгән затлар;<br>4) закон белән йөкләнгән бурычларны тиешенчә үтәмәгән өчен опекун (попечитель) вазыйфаларыннан читләштерелгән затлар;<br>5) әгәр уллыкка (кызлыкка) алу алар гаебе белән суд нигезендә гамәлдән чыгарылган булса, элеккеге уллыкка (кызлыкка) алган затлар;<br>6) сәламәтлек торышы буенча баланы уллыкка ала алмый торган затлар. Затның баланы уллыкка алу, аны опекага яисә попечительлеккә алу, бала алучы гаиләгә яисә патронат гаиләгә алу мөмкинлеге булмаган авырулар исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.<br>7) уллыкка (кызлыкка) алу билгеләнгән вакытка уллыкка (кызлыкка) алучылар яши торган Татарстан Республикасында билгеләнгән баланы тәэмин итәрлек яшәү минимумы кереме булмаган затлар;<br>8) даими яшәү урыны булмаган затлар;<br>9) әлеге өлешнең 10 пунктында каралган очраклардан тыш,<br>шәхеснең җенси кагылгысызлыгына һәм җенси ирегенә каршы<br>җинаятьләр өчен, шулай ук шәхеснең гомеренә һәм сәламәтлегенә<br>каршы, ирегенә, намусына һәм абруена каршы (психиатрия<br>ярдәмен стационар шартларында күрсәтә торган медицина оешмасына законсыз урнаштырудан һәм яла ягудан тыш), гаиләгә | |

| | | |
|---|---|---|
| | һәм балигъ булмаганнарга каршы, халыкның сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлаклылыкка каршы, иҗтимагый иминлеккә каршы җинаятьләр өчен хәзерге вакытта яисә элегрәк хөкем ителгән, җинаять эзәрлекләвенә хәзерге вакытта яисә элегрәк дучар булган затлар (җинаять эзәрлекләве реабилитацияләү нигезләре буенча туктатылган затлардан тыш);<br>10) әлеге өлешнең 9 пунктында күрсәтелгән затлар арасыннан булган, шәхеснең гомеренә һәм сәламәтлегенә каршы, ирегенә, намусына һәм абруена каршы (психиатрия ярдәмен стационар шартларында күрсәтә торган медицина оешмасына законсыз урнаштырудан һәм яла ягудан тыш), гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга каршы, халыкның сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлаклылыкка каршы, иҗтимагый иминлеккә каршы авыр яисә аеруча авыр җинаятьләргә караган җинаятьләр өчен хөкем ителгән йә җинаять эзәрлекләвенә дучар булган затлар, мондый затлар суд тарафыннан уллыкка алына торган баланың гомеренә, сәламәтлегенә һәм намусына куркынычлы дип танылган очракта.<br>11) әлеге өлешнең 9 пунктында күрсәтелгән җинаятьләргә карамаган авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр өчен хөкем ителгән затлар;<br>12) Россия Федерациясе Гаилә кодексының 116 статьясындагы 6 - 10 өлешләрендә билгеләнгән тәртиптә әзерлек узмаган затлар (баланың якын туганнарыннан, шулай ук уллыкка алучы яисә булган һәм аларга карата уллыкка алу юкка чыгарылмаган затлардан һәм | |

| | | |
|---|---|---|
| | балаларның опекуннары (попечительләре) булып торучы яисә булган һәм үзләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдән читләштерелмәгән затлардан тыш<br>13) бер үк җенестәге затлар арасында төзелгән берлектә<br>торучы затлар, ул мондый өйләнешү рөхсәт ителгән дәүләт законнары нигезендә өйләнешү дип танылган һәм теркәлгән булса,<br>шулай ук күрсәтелгән дәүләт гражданнары булып торучы һәм<br>өйләнешмәгән затлар.»;<br>14) **җенесен үзгәрткән затлар.**<br>2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тулы булмаган һәм (яисә) дөрес булмаган белешмәләр бирү, алар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү хокукы билгеләнә торган белешмәләр;<br>3. Бирелгән документларның 2.5 п. күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве.<br>Дәүләт хезмәтен туктатып тору өчен нигезләр каралмаган. | |

2. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының «Опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламенты турында» 2018 елның 29 декабрендәге 381 номерлы (16.10.2019 №300, 09.12.2019 №352, 01.10.2020 №257, 02.04.2021 №74, 06.07.2021 №148 карарлар редакциясендә) карары белән расланган “Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка (кызлыкка) алучыга кандидат буларак исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты»ның 15 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 2.9 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. - Әгәр мөрәҗәгать итүче (ләр) түбәндәге категорияләргә караса:<br>- ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән затлар;<br>- шәхеснең җенси кагылгысызлыгына һәм җенси ирегенә каршы җинаятьләр өчен, шулай ук шәхеснең гомеренә һәм сәламәтлегенә каршы, ирегенә, намусына һәм абруена каршы (психиатрия ярдәмен стационар шартларында күрсәтә торган медицина оешмасына | Россия Федерациясе Гаилә кодексының 146 статьясы<br><br>РФ Хөкүмәтенең 423 номерлы карары |

| | | |
|---|---|---|
| | законсыз урнаштырудан һәм яла ягудан тыш), гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга каршы, халыкның сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлаклылыкка каршы, иҗтимагый иминлеккә каршы җинаятьләр өчен хәзерге вакытта яисә элегрәк хөкем ителгән, җинаять эзәрлекләвенә хәзерге вакытта яисә элегрәк дучар булган затлар (җинаять эзәрлекләве реабилитацияләү нигезләре буенча туктатылган затлардан тыш);<br>- авыр яисә аеруча авыр җинаятьләр өчен кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем ителүе булган затлар;<br>- хроник алкоголизм яисә наркомания белән авыручы затлар, опекуннар (попечительләр) бурычларын үтәүдән читләштерелгән затлар, ата-ана хокуклары чикләнгән затлар, элек уллыкка алучылар, әгәр уллыкка алу аларның гаебе белән юкка чыгарылган булса, шулай ук сәламәтлеге торышы буенча (Россия Федерациясе Гаилә кодексының 127 статьясындагы 1 пункты) бала тәрбияләү бурычларын башкара алмаган затлар;<br>- Россия Федерациясе Гаилә кодексының 127 статьясындагы 6 пунктында билгеләнгән тәртиптә әзерлек узмаган затлар (балаларның якын туганнарыннан, шулай ук уллыкка алучы булып торучы яисә булган һәм аларга карата уллыкка алу юкка чыгарылмаган затлардан һәм балаларның опекуннары (попечительләре) булып торучы яисә булган һәм үзләренә йөкләнгән вазыйфаларны үтәүдән читләштерелмәгән затлардан тыш);<br>- бер үк җенестәге затлар арасында төзелгән берлектә торучы затлар, ул мондый өйләнешү рөхсәт ителгән дәүләт законнары нигезендә өйләнешү дип танылган һәм теркәлгән булса, шулай ук күрсәтелгән дәүләт гражданнары булып торучы һәм өйләнешмәгән затлар.»;<br>- **җенесен үзгәрткән затлар.**<br>2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан | |

| | | |
|---|---|---|
| | тулы булмаган һәм (яисә) дөрес булмаган белешмәләр бирү, алар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү хокукы билгеләнә торган белешмәләр;<br>3. Бирелгән документларның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве.<br>4) балигъ булмаган затны гаиләгә кабул итүгә кандидатның якын туганнарының риза булмавы.<br>Дәүләт хезмәтен туктатып тору өчен нигезләр каралмаган. | |

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Х. Шәмсетдинов